**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карары**

Мәлбагыш авылы № 169 “24” апарель 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советының 2016 елның 15 ноябрендәге 43 номерлы "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең генераль планы турында» карарын гамәлдән чыгару турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2020 елның 12 мартындагы 331-45 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең генераль планы турында" карары нисәпкә алып һәм норматив хокукый актларның кабатлануын булдырмау максатыннан

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советының 2016 елның 12 мартындагы 331-45 номерлы "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең генераль планы турында" карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карар 2020 елның 20 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга http://aznakayevo.tatar.ru//http://aznakayevo.tatar.ru//.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.Ә.Әхтәмова